| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУСЛЮМОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.10.2024 с. Муслюмово № 445

**«Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларнында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 13 июнендәге 276 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районынын гомуми белем биру оешмаларында укучыларны баланслы тукландыру нормаларын утәүне тәэмин итү максатларында, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендэге, 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясын утәү йөзеннән, Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль усеш министрлыгының 213н номерлы боерыгы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгынын 2012 елнын 11 мартындагы 178 номерлы боерыгы нигезендә “Мәгариф учрежденияларында укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне тукландыруны оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында”, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын “Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирунең белем биру программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирунең белем биру программалары буенча укучыларны кайнар тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында” 2023 елның 4 сентябрендәге 1066 номерлы карары белэн Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» 024 елның 13 июнендәге 276 нчы номерлы карарының 2., 3, 4 пунктларына үзгәрешләр кертергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

1.1.«2.Барлык муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 1-4 сыйныф укучыларыу көненә 66,43 сум (алтмыш алты сум 43 тиен) түләүсез кайнар иртәнге аш белән тәэмин итәргә.»;

1.2. «3. Ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы буенча, ГПД да (озайтылган

көн төркемнәрендә) шөгыльләнүче укучылар һәм күрше авыллардан база мәктәпләрендә белем алучы укучыларга 19,90 сум (унтугыз сум 90 тиен) өстәмә туклану оештырырга.»;

1.3. «4. Урта, төп гомуми белем бирү оешмаларында көнгә бер укучыга 5-11 сыйныф укучылары өчен кайнар иртәнге аш бәясен 66,43 сум (алтмыш алты сум 43 тиен) күләмендә билгеләргә, шулардан 9,20 сум (тугыз сум 20 тиен) субсидия».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында ( https://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында.бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң законлы көченә керә.

4. 4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**